Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

1 август 2023 ел №70

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 25 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 25 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2023 елның 20 февралендәге 57 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтада:

а) «Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу» 8 бүлегенең 8.7 һәм 8.8 пунктларында «муниципаль хезмәттән» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

б) 22 бүлекнең 22.6.2 пунктындагы «а» пунктчасын «муниципаль хезмәткәрнең җаваплылыгы» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан уздырылган тикшерү нәтиҗәләре турында докладны 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан;»;

в) «Муниципаль хезмәткәрнең җаваплылыгы» 22 бүлегенең 22.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында әлеге Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый

бурычларны үтәмәгән очракта, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә җаваплылыктан азат ителә»;

г) «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру» 24 бүлегенең 24.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24.5. Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырсалар, йә тулы булмаган белешмәләрне тапшырсалар, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора, моңа федераль законнарда билгеләнгән очраклар керми.»;

д) «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру» 24 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 24.5.1 пункты белән тулыландырырга:

«24.5.1. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге бүлекнең 24.5 пунктында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл Советы башлыгына йөкләргә.

Колшәрип авыл
җирлеге башлыгы — А.Ф. Кәшәфетдинов